ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.03.2023 Олы Кайбыч ав. № 88

Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы муниципаль мәгариф учреждениеләрендә мөмкинлекләре чикләнгән укучыларны ике тапкыр бушлай ашату тәртибен раслау турында»2021 елның 30 сентябрендәге 402 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы нигезендә һәм мөмкинлекләре чикләнгән укучыларга социаль ярдәм күрсәтү максатларында Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының муниципаль мәгариф учреждениеләрендә мөмкинлекләре чикләнгән укучыларга ике тапкыр бушлай ашату тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы башкарма комитетының 2021 елның 30 сентябрендәге 402 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Мөмкинлекләре чикләнгән укучылар өчен ике тапкыр туклану (коры паек) бәясе:

-башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алучылар өчен федераль бюджет акчалары исәбеннән 64,19 сум һәм муниципаль бюджет акчалары исәбеннән 8,80 сум;

- төп һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алучылар өчен Россия Федерациясе субъекты акчалары исәбеннән 8,80 сум һәм муниципаль бюджет акчалары исәбеннән 42,20 сум. »

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:// kaybici.tatarstan.ru веб-адрес буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ф.Ф.Петуховага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров